КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 28

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 24 март, 268 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 24 март, 268 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 1 сентябрь, 944 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «2022» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру тәртибенең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда төзелгән контракт турында мәгълүмат һәм документлар «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә заказчылар белән төзелгән контрактлар реестрына кертелә. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә заказчылар тарафыннан төзелгән контрактлар реестрына кертелгән мәгълүмат һәм документлар сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин